СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№2-16 от «31» октября 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 13 августындагы «Су белән тәэмин итү өлкәсендә коммуналь инфраструктура системаларына карата концессион килешүләр төзү һәм әлеге объектларны концессиягә тапшыру чаралары планын («Юл картасы») раслау турында» №8-8 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге № 115-ФЗ Федераль закон нигезендә концессион килешүләр шартларында муниципаль мөлкәтне куллануга күчүне тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 13 августындагы «Су белән тәэмин итү өлкәсендә коммуналь инфраструктура системаларына карата концессион килешүләр төзү һәм әлеге объектларны концессиягә тапшыру чаралары планын («Юл картасы») раслау турында» №8-8 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Су белән тәэмин итү өлкәсендә коммуналь инфраструктура системаларына карата концессион килешүләр төзү һәм күрсәтелгән объектларны концессиягә тапшыру буенча чаралар планының (“Юл картасы”) 1,2,3,4 пунктларын үтәлү сәбәпле, үз көчен югалтты дип танырга.

1.2. 5, 6, 7, 8 пунктларның үтәү срокларына үзгәрешләр кертергә һәм үтәү вакытын 31.12.2022 елга кадәр дип билгеләргә, 9 пунктта үтәү срокларына үзгәрешләр кертергә һәм үтәү вакытын 20.02.2023 елга кадәр дип билгеләргә, 10 пунктта үтәү вакытына үзгәрешләр кертергә һәм үтәү вакытын 20.04.2023 елга кадәр, 11 пунктта үтәү срокларында үзгәрешләр кертергә һәм үтәү вакытын 2023 елның 20 июненә кадәр дип билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

000092

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының бюджет, икътисадый сәясәт һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе

А.П.Иванов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Советының 31.10. 2022 ел,
№2-16 карарына
кушымта

**Су белән тәэмин итү өлкәсендә коммуналь инфраструктура системаларына карата концессион килешүләр төзү һәм күрсәтелгән объектларны концессиягә тапшыру буенча чаралар планы**
**(“Юл картасы”)**

| № т/б | Чаралар | Җаваплы башкаручы | Үтәлү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Тарифларны җайга салу үзенчәлекләрен исәпкә алып, проектның финанс моделен әзерләү, ә проектның финанс моделе нигезендә – объектларны төзү (реконструкцияләү)/эксплуатацияләүгә чыгымнар Концедентының түләвен билгеләү турында Карар кабул итү. Концессионер эшчәнлегенең минималь рөхсәт ителгән һәм иң чик күрсәткечләрен исәпләү. Тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты тарафыннан конкурс критерийларының иң чик күрсәткечләрен һәм тарифларны җайга салу параметрларын килештерү, шулай ук конкурста катнашучыларның тулаем керемен исәпләү өчен кирәкле бәяләрне һәм күләмнәрне бирү. | «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» ҖЧҖ | 31.12.2022 ел |
| 2. | Килешү буенча тапшырыла торган объектларны эксплуатацияләү һәм үстерү чаралары исемлеген үз эченә алган концедент биремен (беренче елга конкрет һәм алдагы елларга якынча) формалаштыру. Бу расланган су схемалары нигезендә формалаша. Бирем Конкурс документлары составына, шулай ук концессион килешүгә кертелә | Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты (инфраструктура үсеше бүлеге) | 31.12.2022 ел |
| 3. | 2021 елда концессион килешү төзү планлаштырыла торган объектлар исемлеген раслау аны torgi.gov.ru | Мамадыш районының милек мөнәсәбәтләре | 31.12.2022 ел |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сайтында бастырып чыгару | палатасы | |
| 4. | Концессион килешү төзү турында карар проектын әзерләү. Конкурс уздыру турында хәбәр итү, һәм конкурс документлары Концессия килешүе проекты белән бергә. | Мамадыш районының милек мөнәсәбәтләре палатасы | 31.12.2022 ел |
| 5. | Конкурс документларын ( концессион килешү проектын үз эченә ала) һәм конкурс комиссиясе составын ( кимендә 5 кеше) раслау<br>Конкурс комиссиясе составында республика вәкилләре турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән концессия килешүенә кул кую хокукын делегацияләү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгын кабул итү | Мамадыш районы башкарма комитеты Мамадыш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | 20.02.2023 ел |
| 6. | Концессия килешүе төзү хокукына конкурс үткәрү | Мамадыш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | 20.04.2023 ел |
| 7. | Концессион килешү төзү | Мамадыш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | 20.06.2023 ел |